**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ТАШКИЧУЙСКОГО СЕЛЬСКОГО**
**ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГОРАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ ТАШКИЧҮ**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423959, Республика Татарстан,
Ютазинский район, деревня Малые Уруссу,
улица Советская, дом 21А
тел. 85593 4-23-10, факс 85593 4-23-40

423959, Татарстан Республикасы,
Ютазы Районы, Кече Урыссу авылы,
Совет урамы, 21А йорты.
эл.адрес Tash.Utz@ tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**28 января 2022г.** **№ 7**

2022 елга Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегендә
җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге
нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен
раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 1996 елның 12 гыйнварындагы «Җирләү һәм җирләү эше турында»гы 8-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы, 2007 елның 18 маендагы «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 196 санлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Башкарма комитеты к а р а р  и т т е:

1. 2022 елның 1 февраленнән Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегендә әлеге карарның 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымтасы нигезендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеген 6964,68 (алты мең тугыз йөз алтмыш дүрт сум 68 тиен) күләмендә билгеләргә һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен гамәлгә кертергә.
2. Үз көчен югалткан дип таныргга:

- Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 29 гыйнварындагы «2021 елга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында»гы 4 санлы карарын.
- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 01 июнендәге «2021 елның 29 гыйнварындагы 2021 елга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында"гы 4 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы 10 санлы карарын.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru.

4. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемдә тотам.

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Р.К. Вәлиев

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Ташкичү авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2022 елның “28”гыйнварындагы
7 санлы карарына 1 кушымта

2022 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең
гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт исеме | Хезмәтнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Күмү өчен кирәк булган документлар әзерләү. | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2794,15 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (калдыкларын) зиратка илтү | 854,12 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3316,41 |
| Барлыгы | 6964,68 |

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Ташкичү авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2022 елның “28”гыйнварындагы
7 санлы карарына 2 кушымта

2022 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең
гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт исеме | Хезмәтнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Күмү өчен кирәк булган документлар әзерләү. | 0,00 |
| 2. Мәетне кәфенләү, киендерү | 648,45 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2145,71 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (калдыкларын) зиратка илтү | 854,12 |
| Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3316,40 |
| Барлыгы | 6964,68 |